КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 30 май г.Казань № 756

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 30 декабрь, 1251 нче карары белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга тимер юл транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга тимер юл транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2024 ел, 30 декабрь, 1251 нче карары белән расланган Шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртү тарифларын дәүләт тарафыннан җайга салуга бәйле, шулай ук гражданнарның аерым категорияләренә юл йөрү өчен ташламалар бирүгә бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне каплауга тимер юл транспорты оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Министрлыкка җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

47 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Агымдагы финанс елыннан соң килүче елның 25 гыйнварына кадәр субсидия алучы Министрлыкка агымдагы финанс елның декабренә хисаплар тапшыра:

субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган һәм мөһер (булганда) белән беркетелгән Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны элемтәсендә тимер юл транспорты белән пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашырудан башкарылган чыгымнар һәм алынган керемнәр турында һәм дәүләт тарафыннан тарифлар җайга салынуга бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәр күләмнәре (субсидия алучы эшенең техник-икътисадый күрсәткечләре);

субсидия алучының җитәкчесе һәм баш хисапчысы имза куйган һәм субсидия алучының мөһере белән беркетелгән (булган очракта) Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр яны тимер юл транспортында хезмәт күрсәткәндә белем алучыларны йөртүдән алынып бетмәгән керемнәр күләме һәм Татарстан Республикасы территориясендә йөрү өчен түләгән укучылар саны турында хисап;

«Россия тимер юллары» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан килештерелгән шәһәр яны поездларының башкарылган вагон-чакрым эше күләмен раслый торган документлар.»;

49 пунктның дүртенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

54 пунктның беренче абзацында татар текстында «Бирелгән субсидия» сүзләрен «Субсидия акчасы» сүзләренә алмаштырырга;

55 пунктта «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин